СӘЙ ГОМЕРНЕ, СӘЙ ХАЛЫКНЫ, СӘЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНЫН ИЖТИМАГЫЙ СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

Газета 1931 елның 6 июленнән бирле чыга. | №107 (7280) | 7 сентябрь, 1991 ел. ШИМБӘ | Бәясе 4 тиен.

## 6 сентябрьдә халык депутатлары Октябрь район Советының бишенче сессиясе булды

## *Хөрмәтле укучыбыз! Син безнең газетага язылдыңмы?*




Исегезгә төшерәбез: газетаның еллык бәясе— 6 сум 24 тиен, ярты елга —3 сум 12 тиен.

## СССР халык депутатлары съезды эшен тәмамлады

Мәскәү (ТАСС). 5 сентябрьдә Кремльнең Съездлар сараенда СССР халык депутатларының чираттан тыш V съезды эшен тәмамлады.

Йомгаклау утырышында депутатлар «Кеше хокуклары һәм ирекләре Декларациясе»н тикшерделәр һәм кабул иттеләр.

—Бернинди группа, партия яки дәүләт интереслары да кеше интересларыннан югары була алмый, дип ассызыклана документта. Декларация илебезнең барлык гражданнары өчен тигезлек, сүз ирегенә, намуска һәм дингә, политик партиягә, профсоюзларга һәм җәмәгать оешмаларына берләшүгә, власть органнарына сайларга һәм сайлануга хокук гарантияли. Шәхеснең кагылгысызлыгы, торак, язышуларның сер итеп саклануы, шулай ук дәүләт уку йортларында бушлай белем алу, дәүләт сәламәтлек учреждениеләрендә бушлай медицина хезмәте күрсәтү гарантияләнә.

Декларациядә һәр кешенең хезмәткә һәм аның нәтиҗәләренә хокукы, ирекле рәвештә эш сайлау һәм аннан баш тарту хокукы, дәүләт тарафыннан минимум түләүгә һәм эшсезлектән яклауга хокукы күрсәтелә. Моннан тыш, социаль яклауга, шулай ук ялга, социаль тәэмин итүгә хокук гарантияләнә.

Съездда кыскача йомгаклау сүзе белән СССР Президенты М. С. Горбачев чыкты.

## Чыгымнарны каплау турында

Татарстан ССР Премьер-министры М. Г. Сабиров 1991 ел уңышын җыюга тартылган тракторчы-машинистлар, йөк автомобильләре шоферлары, ремонтчы эшчеләр, механиклар, автоколонна начальниклары, диспетчерлар һәм автотранспорт колоннасы составына кертелгән башка работникларга чыгымнарын тәүлеккә 20 сум яки төп эш урынындагы уртача хезмәт хакының 75 проценты күләмендә каплау турында күрсәтмә чыгарды. Күрсәтелгән чыгымнар предприятиеләр, оешмалар һәм учреждениеләрнең үз средстволары исәбенә түләнә һәм колхозларга, совхозларга һәм башка авыл хуҗалыгы предприятиеләренә 1991 елның 1 декабренә кадәр, ә шикәр заводларына 1992 елның 1 мартына кадәр кире кайтару өчен тәкъдим ителә.

Колхозлар, совхозлар башка авыл хуҗалыгы предприятиеләренең предприятиеләргә, оешмаларга һәм учреждениеләргә командировка буенча тоткан чыгымнары ТССР Финанс министрлыгының 1991 елның 25 июль хаты билгеләгән тәртиптә үткәрелә.

## *ИКЕ УҢГАН САВУЧЫ*

Сыер савучылар арасында Җәрия Шәрәпова һәм Әминә Әһлиуллина веручы мактаулылардан санала. Алар фермада өч дистә елдан артык хезмәт куюю дәверендә нинди генә авырлыкларга юлыксалар да, үз профессияләренә тугрылыклы булып калдылар. Бу ике уңган шул ук вакытта башкаларга остаз да. Хәзер алар ярдәмендә сыер савучы профессиясенең нечкәлекләренә өйрәнүчеләр шактый. Бүгенге көндә Җәрия Шәрәпованың кызы Фәридә белән улы Фәргать тә фермага эшкә килделәр.

Үз хезмәтләрен яратып, күңел биреп башкарганга савучыларның нәтиҗәләре дә куанычлы: Җ. Шәрәпова һәм Ә. Әһлиуллина бүгенге көндә һәр сыердан уртача 12 шәр килограмм сөт савалар.

**С. ФӘТХЕТДИНОВА.**
«Комбайн» колхозы.

БАСУ ХӘБӘРЛӘРЕ

## *Икенче урак*

Авыл хезмәтчәннәре өчен икенче урак—чөгендер алу башланды. «Путь к коммунизму» колхозы кырларына да татлы тамырны җыеп алу техникасы чыкты. I бригаданың чөгендер басуында Валерий Ишмуллин звеносы егетләре эшли. Көннәрнең аяз торуыннан нәтиҗәле файдаланып, алар үзләре 148 гектар мәйданда үстергән бу татлы тамырны тиз һәм югалтуларсыз җыеп алу өчен вакыт белән санашмыйлар. КС-6 комбайнында эшләүче Владимир Уфимов белән Владимир Яндуков көнлек нормаларын күпкә арттырып үтиләр. БМ-6 комбайнында чөгендер яфрагын урдыручы Геннадий Афанасьев, Алексей Глухов та тырышып хезмәт куялар. Алар урдырган яфрак массасы терлекләргә азык буларак кулланыла, шулай ук силослана да. II бригадада Александр Микушкин звеносы да бу эшне бик оешкан төстә башлап җибәрде. Александр Комолов, Андрей Петров кебек уңган механизаторлар үз эшләрен белеп, җиренә җиткереп башкаралар.

**М. ЛЫКОВА.**

## Чөгендер алалар

**«Кондырча» колхозы.** Хуҗалык икенче икмәк—чөгендер алуга керешеп китте. Биредә татлы тамыр 160 гектарда игелә. Аның уңышын җыюга хуҗалык әйбәт әзерлек белән килде. Чөгендер чыгаруда Әнвәр Вәлиев, Әсгать Тәмаев, яфрак урдыруда Ислам Галәветдинов, Фәрит Абдуллин, Фәргать Хөсәенов әйбәт кенә темп белән эшләп киттеләр. Чөгендерне кагатка Әхмәт Әхмәдиев һәм Насыйх Ибәтуллин ташый. Быел хуҗалык чөгендер яфрагын силослау белән дә шөгыльләнә. Массаны силос базына Мәүләт Тәмаев ташып тора.

Колхоз шикәр заводына беренче 100 тонна чималны озатты инде. Салих Гомәров төйи, шоферлар Фәргать Вәлиев һәм Ринат Вәлимөхәммәтов заводка озаталар. Басуда чөгендерче апалар да бердәм булып эшли башладылар.

**М. КАМАЛЕТДИНОВ.**

*Авыл хәбәрчеләребез яза*

# АВЫЛ СЕЗНЕҢ БЕЛӘН КӨЧЛЕ



Кечкенә генә бу коллективны мин байтак еллардан бирле күзәтеп, сынап киләм. Биредә башлыча хатын-кызлар гына хезмәт итә дисәң бик үк дөрес булмас. Ир-атлар—механизаторлар, ветеринария хезмәткәрләре, сантехниклар. Әмма терлекчеләр—хатын-кызлар гына.

Терлекләрне үстереп җиткерү комплексында эшләүче бу хатын-кызларны гүя сайлап алганнар, барысы да эш сөючән, уңган, җитез—бер сүз белән әйткәндә булдыклы хатын-кызлар. Үзләре гади, ләкин авылның тоткалары шулар. Чөнки алар җәен-көзен чөгендер эшкәртә, төрле авыр эшләр башкаралар, инде чөгендер бетүгә барысы бергә янә бер коллектив булып тупланып терлекчелеккә эшкә киләләр. Авылда терлекчелек эше читтән караучыларга бик авыр, гел бер төрле, баткаклык сөреп, пычранып йөрү генә шикелле тоела. Әмма, әгәр эшнең ямен-тәмен таба белсәң, эшне дә бәхет итеп санасаң, һич алай түгел ул. Мин боларны шушы коллектив хатын-кызларына карата әйтәм. Эшкә алар бик чиста, зәвык белән киенеп киләләр, өс-башларын алыштырып халатлары белән иртәнге эшкә таралалар һәм барысы бергә эшләрен бер вакытта төгәлләп (берберсенә хәтта булышып) үзләренең терлекчеләр йортына иртәнге чәйгә җыелалар. Биредә язылмаган закон шундый: гадәткә кергән, кем ялдан соң килә (ике көн эштән соң—бер көн ял) ул тәмле-тәмле ризык-нигъмәтләрен пешереп килә, хуш исләрен аңкытып күп вакыт өстәлгә бәлеш менә, тәмле чәй исе тарала. Кош теле, бавырсак, юка, өй пироглары—биредә көндәлек ризык. Туган көннәр, бәйрәмнәр — һәркайсы шатлык, муллык белән сый тулы табын артында уен-көлке, җыр-бию белән уза.

Инде килеп берәрсенең авыр эше, кайгы-хәсрәте була-нитә кала икән—бусы да уртак. Эш урыны—гаилә, йортың кебек бит ул. Әгәр эшеңдә тыныч булса, хезмәттәшләрең тату, дус булып үзара ярдәмләшеп эшләсәң, эшкә баруы да күңелле, яшәүләре дә рәхәт.

ТӘНЗИЛӘ МИФТАХОВА. Язмамның төп герое итеп аны күрсәтәм икән, бу дөрестән дә шулай. Бу коллективның күп еллардан бирле бергә тупланып, тату яшәп килүендә Тәнзиләнең роле гаять зур. Араларында үзенең уңганлыгы, җитез-чаялыгы, тапкырлыгы белән аерылып, үзенә җәлеп итеп тора ул. Балачагы әбисе белән әнисенең җылы кочагында үтсә дә, үсмер еллары (15 яшеннән бирле) сыерлар янында үтә аның. Эшкә тотынуын үзе болай дип сөйли ул: «Тәмле төшләр күреп йоклап яткан чагымда, таң йокыларымны бүлеп, кияүгә чыгып киткән сыер савучыны алыштырыр өчен ул вакыттагы ферма мөдире Сабирҗан абый Мөхәммәтҗанов атка утыртып җәйләүгә алып китте. Йоклый-йоклый арбада селкенеп баруларым әле дә булса исемдә»...

Бүгенгесе көндә аның 25 еллык эш стажы бар. Шуларның алты елын санамаганда (мәктәптә буфетта эшләп алган еллар), калганнары—терлекчелек һәм чөгендер игүдә үткән.

Бу карап торуга үткен хатын—үзенең киң күңелле, юмарт булуы белән күпләрне бер карауда әсир итә. Үзе кебек уңган-булган тормыш иптәше Рәшит белән эш сөючән, акыллы, тәртипле, 3 бала тәрбияләп үстерде. Гаиләсендә дә эштәге кебек тәртип, чисталык, пөхтәлек, килмәгән җире юк. Гаиләнең тоткасы, таянычы. Коллективта барысы да аңа таяна, аның белән киңәшә икән—димәк аңарда тумыштан ук бирелгән кешеләрне оештыру, туплый белү сәләте бар. Үзешчән сәнгать түгәрәгендә, төрле кичәләрдә дә башлап йөрүчеләрдән ул. Хатын-кызлар советы члены һәм башка җәмәгать эшләрендә дә бик актив хатын.

ГАЛИЯ МУСИНА—Тәнзиләнең яшьлек дусты, яшьтәше, хезмәттә уң кулы. Икесе дә бер характерлы, якты карашлы, гади, шул ук вакытта һәрнәрсәгә гадел, туры сүзлеләр. Галия дә Тәнзилә кебек чая, тапкыр, уңган-булган хатын. Ул да 8 классны тәмамлаганнан бирле шушы авылда, колхозда бер карусыз авыр эшләр башкарып, аһ-зарсыз, тормышның ямен, тәмен тоеп булганына шөкер итеп яши торган кеше. Егерме елдан артык каенанасы белән күпләрне сокландырырлык, тату гомер кичереп, авырганда сабый баладай багып, кадер-хөрмәт күрсәтеп быел соңгы юлга озатты. Гаиләсендә үзе кебек уңган механизатор—тормыш иптәше белән тату, тигез гомер кичереп, 3 бала тәрбияләп үстерделәр. Бу гаилә турында авылда күзгә-күз карашып, бер-берсен аңлашып яшәүчеләрнең берсе дип сөйлиләр. Ансамбль чыгышлары, төрле кичәләр Галиясез үтсә, нидер җитешми кебек.

КАДРИЯ АЛИЕВА—Тәнзилә белән Галиянең яшьтәше, дуслар. Тәнзиләнең ут күршесе булып гомер итә. Алардан аермалы буларак, Кадрия басынкы характерлы, аз сүзле. Ләкин уңган, эштә карусыз хатын. Ул да 15 яшеннән бирле сыерлар савып, күп балалы гаиләдә тормышның ачысын-төчесен татып, гаилә коргач та үз хәләл көче белән көн итеп, булганның кадерен белеп яши торган булдыклы хатын-кыз. Авылда Кадрия яши торган ихата яныннан узганда аның гөлбакчасына, шул бакчада үскән төтәл-төтәл яшелчәләргә хозурланып, ул юып элгән керләрнең аклыгына сокланып үтмәүче юктыр, мөгаен. Коллективта ул тыныч табигате, карусызлыгы, тыйнаклыгы белән аерылып тора.

Гаиләсендә 3 бала анасы, иренең сөйгән хатыны. Бер-берсен санлашып, ихтирам итешеп яшиләр алар тормыш иптәше белән.

ГӨЛНУР ӘХСӘНОВА—тумышы белән Түбән Норлаттан, күрше авыл кызы. Яшьли килен булып төшкән яшьтәшем Гөлнурга мин күп еллардан бирле сокланып яшим. Шушы авылга килгәннән бирле Гөлнур чөгендер игә, төрле авыр эшләр алар җилкәсендә—кышларын силос-сенаж базлары ачу, салам тапату, тегермән тарттыру, язларын чәчүлек әзерләү, катнаш азык ташу, агарту-буяу эшләре һәм башкалар, һәм башкалар. Авыл шундый хатын-кызлар, шундый карусызлар белән яши. Өендә һәр эшкә өлгерүчәнлеге, җитезлеге белән, эшендә дә шул ук сыйфатлары, әчкерсезлеге, ачык йөзлелеге белән аерылып тора. Берсеннән-берсе чибәр ике кыз үстереп, тормыш иптәше белән тигез, мул тормышта яши. Ләкин бүгенгесе көндә Гөлнур авыр операция кичерде. Тормышны яратучан, эшчән, нык ихтыяры сырхауларга бирешмәс. Авырмас сөяк булмас, авылдашлары аның савыгуын көтәләр.

ӘЛФИЯ ХИСАМОВА—эшчән гаиләдә туып-үскән кыз. Бу гаиләдә алар 6 кыз үскәннәр. Алтысы да сылу, чибәр, итәгатьле, инсафлы, уңган кызлар. Әлфия, иң өлкәне буларак, әнисенең кул арасына да яшьли керә. Бер мәл авылда яшьләр калмый башлаган чорда, яшьтәшләре арасында беренчеләрдән булып үрнәк күрсәтеп терлекчелеккә дә, чөгендер игәргә дә шундый чорда керешә. Бүгенгесе көндә инде аның 15 еллык терлекчелек стажы бар. Гаиләсендә—яраткан хатын, улына һәм кызына—кадерле ана.

ГӨЛСЕМ апа МИФТАХОВА. Тәнзиләнең килендәше, хезмәттәше, хәтта серләре сыярлык сердәше дә. Бу өч тату, уңган, бар яклап ихтирамга лаек, үрнәк булырлык килендәшләр турында аерым бер очерк язарлык. Үзара тату, ярдәмләшеп, кайгы-шатлыкларын уртак бүлешеп яшәүче килендәшләргә авылда һәркем соклана.

Гөлсем апа—араларында иң олысы, ачык йөзле үтә уңган хатын. Аның турында авылда бер сүз белән: «Киң холыклы»,—диләр. Дүрт бала анасы, туры сүзле, гадел карашлы. Олыгаеп килүенә карамастан, кызлар кебек зифа буйлы, чибәр йөзле бу хатын килендәшләре һәм хезмәттәше МИНҖИҺАН апа САФИНА белән сәхнәгә менәргә дә вакыт таба. Алар катнашкан кичәләр уен-көлке, җыр-бию белән үтә. Инде эш стажлары да 30 елдан артык аларның. Гомер юлларын да бергә аралашып, дус-тату яшәп, ярдәмләшеп узалар. Минҗиһан апа да дүрт бала тәрбияләп үстерде, тормыш иптәше ветеринария хезмәткәре Әсхәт абый белән күгәрченнәрдәй гөрләшеп, бер-берсен аңлашып, чын мәгънәсендә җырлашып яши бу гаилә. Әсхәт абый—авылның атаклы гармунчысы, ә Минҗиһан апа бик матур җырлый. Аларның бу сәләте кызлары Миләүшәгә дә күчкән. Гомумән, гаиләләре белән җырлы-моңлылар.

Тагын ике килендәш—ВӘЛИМӘ һәм МАЛИЯ ЗӨЛКӘРНӘЕВАЛАР да эшли бу коллективта. Аларның да гомер юллары терлекчелек, чөгендерчелек белән бәйләнгән. Алар да инде 30 елдан артык колхозга хезмәт итүче, уңган хатын-кызлар. Икесе дә 4 әр ул һәм кыз үстереп олы юлга озаткан аналар. Малия апа бүгенгесе көндә дә (инде үзе күптән әби булуына карамастан) каенана белән тату гомер кичерә, гаиләсендә тотка булып тора. Килендәше Вәлимә апа белән өйдә дә, эштә дә кайгы-шатлык, көенеч-сөенечләрне уртаклашып яшиләр.

ХАЛИСӘ апа МӨХӘММӘТОВА да авылда һәм коллективта ихтирамга лаек, тыйнак хатын-кыз. Аны уңганлыгы, карусызлыгы, гаделлеге өчен, өйдә каенанасына—карусыз килен, авыру баласына — алыштыргысыз, түземле, нык ихтыярлы ана булганы өчен бар авыл хөрмәт итә.

Шулай ук уңган, эшчән МИННИСА апа МӨХӘММӘТОВА да эшли бу коллективта. Иптәшләре аны һәрвакыт ярдәмгә атлыгып торуы өчен, тыныч табигате, карусызлыгы өчен хөрмәт итәләр.

МИННЕРУЙ апа МӨХӘММӘТШИНА коллективта иң гади, иң киң күңелле, һәрчак мөлаем, ачык йөзле хатын-кыздыр. Һич кемгә авыр сүз әйтмәс, гомерен эшкә багышлаган олы җанлы ананы авылда олысы-кечесе ихтирам итә.

ЗӨЛФИРӘ КӘБИРОВА белән НУРЗИЯ ГОМӘРОВА—авылга читтән төшкән киленнәр, ләкин шушы авылда туып-үскәннәр диярсең, икесе дә уңган-булган, икесе дә җитез, чая. Эшкә дә куллары ятышып тора. Өйләрендә дә чиста, пөхтәләр. Икесе дә икешәр кечкенә бала тәрбиялиләр. Терлекчелектә дә, чөгендер басуында да эшлиләр.

Һәм, ниһаять коллективтагы ике НУРАНИЯ турында язарга да чират җитте. Беренчесе—алда язып кителгән Тәнзилә һәм Гөлсем апаның килендәше, коллектив җитәкчесе НУРАНИЯ МИФТАХОВА. Авылга Зеленодольск якларыннан төшкән килен. Бу хатынның белмәгән эш-һөнәре юк, коллективның дус-тату яшәвендә һәм эшләвендә дә өлеше зур. Өч бала анасы, иренә тугры тормыш иптәше, каенана һәм каената белән уртак тел табып яши.

НУРАНИЯ ГЫЙМАДИЕВА араларында әле чагыштырмача яше. Ләкин эшкә дигәндә үтә уңган. Коллективның алыштыргысыз кешесе дисәк ,ялгыш булмас—ул хезмәттәшләрен дә ял иттерә, чөгендерен дә үстерә, гаиләсендә дә бик бәхетле. Ире Наил—хуҗалыкның алдынгы механизаторы, бер кызлары һәм игезәк уллары үсеп килә, тормышлары сокланырлык матур.

Наил—гармунчы, ә Нурания бик матур җырлый, балалары да җырлы-моңлы. Аларның гаилә ансамбле чыгышы сәхнәдә көтеп алынган кунак кебек.

Коллективның тагын бер члены ветеринария фельдшеры РӘМИЛӘ ВАХИТОВА—Буа якларыннан. Коллективта аны тиз арада үз иттеләр. Терлекләрнең көр, таза үсүләрендә аның өлеше зур, эшчән, сүзчән, кешеләр белән тиз аралашучан. Биредә үзара низаг, аңлашылмаучанлык, эштә килеп чыккан чатаклыклар һәрвакыт уртага салып хәл ителә. Үпкә, гайбәтләргә бу коллективта урын юк. Җитәкчеләр белән уртак тел табып, беренче урынга эш мәнфәгатен куеп эшлиләр.

Менә шундый дус-тату коллектив бар безнең хуҗалыкта. Хатын-кызлар—берсеннән-берсе уңган-булган, хөрмәткә лаек кешеләр. Мин бүгенге язмама хезмәт күрсәткечләрен расләгән саннарны кертмәдем. Эш нәтиҗәләре дә бик күркәм аларның. Ләкин коллектив өчен иң мөһиме, коллективның көзгесе—кешеләрдәге кешелек сыйфатлары, үзара дуслык, хөрмәт итешә белү бүгенгесе көндә.

Алар турындагы бу язмамны шигъри юллар белән тәмамларга булдым.

Шушы җиргә безнең
тирләр тамган,
Маңгайларга сырлар уелган.
Хуҗалыкның барлык
тармагына
Хезмәт көче сезнең куелган.
Олыгаеп инде килсәгез дә,
Һәркайсыгыз хезмәт ярата.
Күңелләрдә бөреләнә бүген
Рәхмәт хисе сезгә карата.

**Ф. МӨХӘММӘТОВА.**
Югары Норлат авылы.

# Яңа уңышка—ныклы нигез

Урак өсте артта калды. Безнең колхоз өчен ул канәгатьләнерлек булмады: бөртекле һәм бөртеклекузаклылар уңышы— бер гектарга уртача нибары 13,4 центнер тәшкил итте. Әмма катлаулы шартларда да уңыш алуны күтәрү мөмкинлеге бар әле. Моны басулар үзе күрсәтте. Уҗым культуралары, мәсәлән, чагыштырмача югары бөртек бирде: арыш гектардан 16, көзге бодай 24,4 центнер чыкты. Әлеге нәтиҗәләрне исәпкә алып киләсе елга уҗым культураларын чәчү мәйданнарын мөмкин кадәр арттыру билгеләнде. Аны 1360 гектарда чәчү планлаштырылды.

Уҗым чәчүгә җәйдән үк ныклы хәстәрлек алып барылды. Чиста пар җирләре җәй барышында берничә кабат эшкәртелде. Шамил Сафин, Сәхип Хәмитшин, Камил Ибраһимов, Илшат Нигъмәтуллин, Рөстәм Хәйруллин культиваторлар белән бу мәйданнарны технология таләпләренә җавап бирерлек итеп эшкәрттеләр. Җәй коры килү сәбәпле борчак, берьеллык үләннәрдән бушаган мәйданнарны эшкәрткәндә зур-зур кантарлар барлыкка килде. Радик Мифтахов, Рөстәм Ситдыйков, Замир Хәмәтвәлиев, Җәүдәт Тахиятуллин бу участокларны БДТ-3 лущильниклары белән ике юнәлештә ваттырып туфракны йомшарттылар. Рөстәм Нуруллин, Рафаэль Дәүләтшин, Илдус Насыйбуллин агрегатлары тырмалар белән туфракны тигезләде.

Чәчү өчен кучмә фондтан чәчү стандартының 1 классына җавап бирүче орлык файдаланылды. Җиргә «Чулпан» сортлы арыш, «Харьковская-808», «Мещенская» көзге бодай орлыгы күмдерелде. Күмдерү өчен СЗП-3,6 чәчкечләре файдаланылды. Вәгыйзь Шәрәпов, Рамил Фәйзуллин, Зиннәт Вафин агрегатлары көн саен 28 урынына 30—35 гектарда бөртек күмделәр. Барлык мәйданга һәр гектарга 100 килограмм исәбеннән катлаулы ашламалар: аммофос һәм икеләтелгән суперфосфат кертелде. Механизаторлар Рәис Вафин, Ришат Сәйфуллин чәчү агрегатларын орлык, ашлама белән тәэмин иттеләр. Чәчүчеләр Хәлим Яруллин, Зариф Фәссахов, Галим Әхмәтҗанов, Идрис Шәфигуллин, Рифкать Вафин, Анатолий Сафронов, Равил Баһаветдинов орлык һәм ашламаның җиргә нормаль керүен күз уңында даими тоттылар. Табигатьне һәм җирле шартларны исәпкә алып, гектарга арыш 4—4,5 миллион, уҗым бодае 6—6,5 миллион бөртек күмдерелде. Бу вегетация чорында чүп үләннәргә үсәргә ирек калдырмау өчен дә оптималь норма сапала.

Чәчү оптималь срокларда башкарылды. Биләүле пар җирләрендә ул 10—20 августта үткәрелде. Чиста пар участокларына орлык күмдерү 20 августтан соң уздырылды. Барлык бу эш август аенда тәгәлләнде. Шытым тигез чыксын өчен чәчелгән мәйдан боҗралы катоклар белән тигезләп калдыра барылды. Аны Әдип Фәттахов, Ибраһим Хөсәенов, Рәшит Зарипов үткәрделәр.

Уҗым культуралары 1560 гектарда чәчелде. Уңыш бирүчәнлеген исәпкә алып, көзге бодай мәйданы 760 гектарга кадәр җиткерелде. Чәчелгән мәйданнарның күпчелек өлешендә уҗымнар бердәм булып тишелде инде. Бу әлеге чәчүлекләрнең кышка ныгып һәм сабакланып, ягъни чыдам булып кереп калуына ышаныч тудыра. Соңгысы, үз нәүбәтендә, киләсе елда тотрыклы уңыш алуга ныклы нигез.

**Җ. ХӘЙРУЛЛИН.**

XXI партсъезд исемендәге колхоз.

# Чөгендер яфрагыннан силос

**Белгеч киңәше**

Быел елның коры килүе сәбәпле, хуҗалыкларда кышлату чорына терлек азыгы, бигрәк тә сусыл азык ким булачак. Моны күпмедер тулыландыру йөзеннән өстәмә азык ресурслары, мәсәлән, чөгендер яфрагы хәзерләргә була.

Районда үстерелгән 6900 гектар мәйдан җирдән югалтусыз чөгендер җыеп алу бурычы тора. Һәм монда тамыразык белән бергә терлек азыгына файдалану өчен яфрагын да хәзерләргә кирәк. Сусыл азык буларак бигрәк тә шикәр чөгендеренең яфрагы кыйммәткә ия. 1 килограмм яфракта уртача 0,12 азык берәмлеге, 15 грамм үзләштерелә торган протеин, 7—8 грамм шикәр, 40—60 миллиграмм каротин, 700 миллиграмм С витамины һәм микроэлементлар бар. Аның аминокислота составы да бай.

Клетчаткасы аз, протеинга, витаминга бай булуы һәм шулай ук яхшы үзләштерелүе чөгендер яфрагын мөгезле эре терлекләрнең генә түгел, дуңгызларның да азык рационында нәтиҗәле файдаланырга мөмкинлек бирә. Шикәр чөгендере яфрагының 2,5 процентын шикәр тәшкил итә, шуңа күрә аны силосларга мөмкин.

Безнең шартларда чөгендер яфрагын җыюны механикалаштыру аны туфракка бутамыйча җыеп алу һәм тулысынча азык буларак куллану мөмкинлеге бирә. Силослаганда яфрак массасының дымлылыгын исәпкә алу мөһим. Әгәр ул 75 проценттан артмаса, аны өстәмә коры азык кушмый гына силосларга да мөмкин. Әгәр инде дымлылык 83—85 процентка җитсә, бу очракта силослана торган массага 10—15 процент (яфрак күләменә карап) коры азык—кибәк яисә вaклатылган салам кушарга кирәк. Бу катнашманы яхшылап бутыйлар һәм тыгызлыйлар. Саклау базының түбән өлешенә коры азыкны күбрәк (15 процент), ә өске өлешенә кимрәк (10 процент) салырга кирәк. Силослаган массадагы кузгалак кислотасының күләмен киметү өчен, силослау процессында 1 тонна яфракка 0,5 килограмм исәбеннән төелгән акбур кушарга, тәмен яхшырту өчен тоннасына 1,5—2 килограмм аш тозы өстәргә кирәк. Өске катламны коры азык кушмыйча гына салып, пленка белән капларга киңәш ителә. Аның өстенә туфрак салып базның яхшы томалануына һәм үз чиратында азыкның яхшы саклануына ирешеп була.

Силослауның бөтен технологик таләпләрен үтәп эшләнгән 1 килограмм яфрак массасында 0,16 азык берәмлеге, 2 грамм үзләштерелә торган протеин һәм 40—50 миллиграмм каротин булырга тиеш.

**Х. ХАЛИТОВ,**

авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе агрономы.

# Колхоз үзгәрә

«ЗАВЕТЫ ИЛЬИЧА» колхозында матур үзгәрешләр бар.

Зүзәй, Сәләңгеш авыллары янынннан гына зур асфальт юл үтә, шуңа күрә бирeдәгеләрне юл проблемасы артык борчымый. Аннан, юллар төзү механикалаштырылган күчмә колоннасы эшчеләре 200 метр мәйданда быел үзәк усадьбада асфальт җәю эшләре башкардылар. Хуҗалыкта фермага баручы юллар да асфальтланган.

Бүгенге көндә колхозның машина-тракторлар паркында көнкүреш хезмәте күрсәтү комплексын төзү тәгәлләнеп килә. Биредә сауна, ашханә, кызыл почмак, ял итү бүлмәләре булачак. **Г. РӘХИМОВА.**

«Рассвет» совхозының икенче товарлыклы-сөтчелек фермасында И. Туктамышев җитәкчелегендәге аренда звеносы 1988 нче елда оешкан иде. Шул көннән башлап ул яхшы гына эшләп китте. Биредә арендачылар Җәмилә Сәйфуллина, Зөһрә Яруллина, Дания Лотфуллина, Минсылу Хәнәфиева вакыт белән исәпләшмичә эшлиләр.

Минсылу Хәнәфиеваның (рәсемдә) фермага килүенә инде дистә елдан артык. Шул еллар эчендә ул үзен намуслы, уңган сыер савучы итеп танытты. Ел башыннан бирле һәр сыердан 2352 килограмм сөт сауды. Бу узган елның шул чоры белән чагыштырганда егерме килограммга артык дигән сүз.



# Эш тагаракка төртелде

Шәһәр мунчаларының нормаль эшләмәве турында сөйли-сөйли дә, яза-яза да ардык инде. Анда хәл әкияттәге сумалага эләккән саесканныкы шикелле: аның бит, мәгълүм булганча, томшыгын алса койрыгы сумалага ябыша, койрыгын алса—томшыгы. Мунчалар белән дә шул ук: кайсында пары, кайсында суы юк. Аларын көйләгән арада я краны ватыла, яисә тагын күздә тотмаган кирtә килеп чыга.

2 сентябрь көнне тимер юлчылар мунчасына баргач, касса бүлмәсе тәрәзәсенә ябыштырылган сәер белдерүгә тап булырга туры килде. Аның эчтәлеге түбәндәгедән гыйбарәт, тагараклар җитешмәү сәбәпле, юыну өчен аны өйдән алып килүебезне үтенәләр.

Хәер, моның өчен әлеге мунча работникларын гына гаепләү нигезле булмас иде. Беренчедән, алар башка мунчаларда да җитешми. Икенчедән, тагаракларны көндез шәм яндырып эзләсәң дә таба алмыйсың.

Сүз мунчада юыну хакында гына барса, бу хакта язып торуның хаҗәте дә калмас иде шикелле: өйдән тагарак алып бардың да— бетте-китте, вәссәләм. Тик бу очракта да «ләкиннәр» бар. Мунчадан ерак яшәүчеләр, мәсәлән, шәһәрнең бер башыннан икенчесенә кадәр тагарак күтәреп йөрсенме? Карт-коры, карчык-корчыкка бу өстәмә мәшәкать. Шәһәргә килүче-китүчеләр ни эшләргә тиеш?

Тагарак хакында бер сүз кузгаткач, мәсьәләнең икенче ягына да кагылмый булмый. Тагарак коммуналь служба өчен генә түгел, һәр хезмәт коллективына, шул исәптән балалар учреждениеләре өчен бигрәк тә, кирәк. Сәүдә работниклары шуны да истән чыгармасыннан иде.

**Р. ЗАҺРЕТДИНОВ.**

# Көндәшеңне көчсез санама

Якташларыбызның соңгы уены нәтиҗәләрен ишеткәч, күңелемдә шундый фикер туды. Моны укучы да тиз аңлар дип уйларга кирәк, чөнки Казанның «Смена» командасы җәй буе аутсайдерлар рәтендә килде. Аның турнир хәле алда тәкъдим ителгән таблицада ачык күренә һәм шул хәл сменалыларны бирни белән санашмый уйнарга мәҗбүр иткән күрәсең.

Хәер, бу очрашуга уенның шаһите, безнең команда начальнигы Александр Хардин аңлатма бирә: Хәзер «Смена» өчен һәр очко кыйммәт, шуңа күрә алар үзләрен кыю тоттылар, һөҗүм тактикасы беләп уйнадылар. Безнең уенчылар да бу командага игътибар бирeп җиткермәде. Беренче тайм уртасында хуҗалар безнең капкага туп кертте.

Уенның калган вакытында «Факел» җыйнакланды. Беренче тайм тәмамлану алдыннан Газинур Хәмидуллин җавап тубы кертте. Икенче таймда Альберт Кашапов исәпне безнең файдага үзгәртте.

**Футбол күзәтү**

«Факел» чираттагы уенын кабат читтә Ковылкиноның «Спартак» командасы белән үткәрде. Газета укучыларның соравын исәпкә алып, Россия һәм ТССР беренчелегенә уеннарның таблицасын тәкъдим итәбез.

**Р. АЙЗАТУЛЛИН.**

### ТССР БЕРЕНЧЕЛЕГЕ

Беренче багана—1 группада команда тоткан урын, икенче, өченче—команда һәм шәһәр исеме, дүртенче, бишенче—уеннар һәм туплаган очколар саны.

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1. | «Прогресс», Зеленодольск | 14 | 26 |
| 2. | «Факел», Норлат | 13 | 20 |
| 3. | «Авангард», Зеленодольск | 12 | 17 |
| 4. | «Торпедо», Алабуга | 14 | 15 |
| 5. | «Нефтехимик», Түбән Кама | 11 | 11 |
| 6. | «Электрон», Әлмәт | 11 | 11 |
| 7. | «Энергетик», Бөгелмә | 11 | 10 |
| 8. | «Смена», Казан | 12 | 4 |
| 9. | «КамАЗ», Чаллы | 14 | 3 |
| 10. | «Восток», Чистай | 14 | 2 |

### РСФСР БЕРЕНЧЕЛЕГЕНӘ

Беренче багана—РСФСР берңчелегенә бишенчезона ярышларында командаларның тоткан урыны, икенче, өченче—команда һәм шәһәр исеме, дүртенче, бишенче—уеннар һәм очколар саны.

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1. | «Текстильщик», Ишеевка | 21 | 36 |
| 2. | «Прогресс», Зеленодольск | 21 | 32 |
| 3. | «МГУ», Саранск | 20 | 27 |
| 4. | «Резинотехника», Саранск | 21 | 27 |
| 5. | «Факел», Норлат | 21 | 25 |
| 6. | «Спартак», Ковылкино | 20 | 20 |
| 7. | «Буревестник», Йошкар-Ола | 20 | 19 |
| 8. | «Торпедо», Алабуга | 20 | 19 |
| 9. | «Волгомаш», Сызрань | 20 | 19 |
| 10. | «Волга», Чабаксар | 21 | 19 |
| 11. | «Химмаш», Рузаевка | 21 | 18 |
| 12. | «Локомотив», Бозаулык | 20 | 18 |
| 13. | «Спутник», Алатырь | 21 | 16 |
| 14. | «Энергия», Чабаксар | 20 | 13 |
| 15. | «Лада», Димитровград | 21 | 11 |

# Кич утырганда

**Безнең бүгенге сәхифәбез өлкәннәргә—тормыш сынаулары узган, катлаулы гомер юлы үткән әби-апаларга багышлана. Балалар үстергән, гаилә терәге булып дөнья йөген тарткан, турылыклы хатын буларак ихтирамга лаеклы, авылларыбызның рухын саклаучы, уңган, тыйнак татар хатыннары, ак яулыклы сөйкемле әбиләребез, безнең шигъри мәҗлескә рәхим итегез!**

**Р. Айзатуллин**

## Тынып калган авыл урамнары

Авылыма кайттым еллар узгач,
Туган якны күңел сагынган.
Хатирәләр үтте йөрәк аша
Ялан тәпи узган чагымнан...
Тынып калган авыл урамнары:
Этләр калмый өреп, озатып;
Карчык-корчык кына каш өстенә
Кулын куеп кала, күз атып.
Күп капкага эленгән зур йозак,
Тәрәзәләргә такта сугылган;
Буш бакчада үсә чүп-үләннәр
Башаклары биек сузылган.
Урамнарда ерым: тракторлар
Колеялар салган эзләр дә.
Сагыш сала бары күңелләргә,
Яшь китерә кырыс күзләргә.
Тынып калган авыл урамнары
Без бәхет эзләгән елларда.
Табылмады бәхет: онытылган авыл,
Туган нигез, аңа юллар да...
Торгызырга аны бик күп кирәк:
Җиргә гашыйк кеше, еллар да...

**Әбиләр-апалар арасында шигърият яратучылар һәм үзләре дә язучылар аз түгел. Әмма аларның бу иҗатлары күпчелек очракта үзләренең дәфтәрләрендә генә кала. Ә бит бу язмаларга аларның күңел сере, җан авазы, гомер сагышы салынган. Өлкәннәребез үзләренең шушы хәзинәсен безнең белән дә уртаклашсалар нинди яхшы булыр иде. Редакция сездән хатлар көтә, мөхтәрәм хатын-кызларыбыз.**

**БЕЛДЕРҮ**

**Милек һәм хуҗалык итү формасыннан бәйсез рәвештә барлык предприятие һәм оешма җитәкчеләре, кооперативлар, фермерлар, колхозлар, совхозлар, кече предприятиеләр һәм индивидуаль хезмәт эшчәнлеге белән шөгыльләнүче гражданнар игътибарына!**

**РСФСРның пенсия фондының Октябрь районы бүлекчәсе бу белдерү басылып чыкканнан соң 10 көн эчендә сездән яңадан теркәлүегезне сорый. Түләүчеләрнең теркәлүе түбәндәге адрес буенча үткәрелә: Норлат шәһәре, Советская урамы, 98.**

**Теркәлү өчен «Экономика и жизнь» газетасының 28 июль 1991 елгы санында бирелгән «РСФСР пенсия фондына предприятие, оешма һәм гражданнарның страховой взнослар түләү тәртибе турында»гы вакытлы инструкциядә каралган формада 2 экземплярда гариза бирү шарт.**

**Теркәү вакытында кирәкле консультация дә бирелә,**

**Взносларны җирле банк бүлекчәсенә 807701 счетына күчерергә кирәк.**

## Ядкарем

Берсе артыннан берсе үсә бара
Тормышка ямь биргән балалар.
Шул балалар кеше булсын диеп
Күпме хәсрәт күрә аналар.
Зур өметләр белән үстерә ул
Бишек җыры җырлап бәбиен.
«Бала хәсрәте ачы була»,—диеп
Бигрәк дөрес әйткән әнием.
Һәрбер ана газиз баласына
Тәүфыйк, бәхет, гомер телидер,
Картлыгында бала хәсрәтеннән
Елыйсылар барын белмидер.
Авыр сүзләр әйтеп рәнҗетмәгез
Әниләрнең печкә күңелен.
Авыр кайгыларга сабыр итеп,
Сезгә бирә бөтен гомерен.

**Миңнеруй Мостафина**

**58 яшь. Норлатта яши.**

Яхшылыгын күреп шатланасың,
Кайгысына сабыр итәсең.
Дөнья булгач төрле хәлләр була,
Анысына нихәл итәсең.
Инде гомер үтеп китте хәзер,
Күп калмады яшәү дәвере.
Кайгы-хәсрәтләргә сабыр иттек,
Булсын иде инде әҗере.
Әй, ходаем, калган гомерләргә
Бир исәнлек, шатлык, тынычлык,
Улга-кызга тәүбә, тәүфыйк иңдер,
Без үлгәчтен дога кылырлык.

Күпме назлар ана йөрәгендә,
Сабырлыкка тиңдәш юк аңа.
Йөрәк түрендәге шушы сүзләр
Ядкарь булып калсын дөньяда.



Авыл көзе. Н. Туганов фотосы.

**Тимерша ВАХИТОВ.**

## *Шифаханә*

Ятәм мин шифаханәдә
Уйланып, гел пошынып.
Әйтәм: ходай, минем язмы
Инде менә шушымы?
Ята-ята хәлләр бетә,
Өмет итеп көн үтә.
Бүген дөньяда яшәсә
Кешегә шул да җитә.
Ятабыз монда икебез—
Мин үзем һәм язмышым.
...Тәрәзәдән ургып керә
Якты дөнья тавышы.
Һай, дөнья, һай,
якты дөнья!
Туйдым бит синнән, дисәм,
Берүк ышана күрмә син:
Шатланам: мин бит исән!

Казан шәһәре.

## *Ана сагышы*

**Бу юлларның авторы—улын югалту кайгысын кичергән карт ана, Биккол авылыннан Рокыя апа Шәрәпова. Бәетне тулысынча бирү мөмкинлегебез юк, чөнки ул 100 гә якын строфаны берләштерә һәм һәр көнне хәсрәтен басарга телигән ана йөрәгеннән чыккан яңа юллар өстәлә тора. Бәетне газета укучылар игътибарына тәкъдим итәбез. Шуның белән күп аналарның аның күңелен аңлап, хәсрәтен җиңеләйтердәй юату сүзе әйтәсенә ышанабыз. Сабырлык һәм түземлелек сезгә, Рокыя апа!**

И балам, күрәсем килә
Тулы гәүдәң, йөзләреңне.
Үлем сөреме саргандыр
Серле кара күзләреңне.
Агыйделнең аръягында
Үсә микән тал-тирәк?!
Бу кайгыларга чыдарга
Тагын бер йөрәк кирәк.
Сайра әле, сандугачым,
Син бит моңлы сайрыйсың.
Башымдагы кайгыларны
Гына миннән алмыйсың.
Кая бардың дип сорамыйм,
Сандугач баласыннан.
Ул да шулай минем кебек
Аерылган баласыннан.
И бер күрешергә диеп
Талпына минем күңел.
Никадәрле талпынса да
Күрергә мөмкин түгел.
Бузин чәчәкләрен өзеп,
Түшемә кадамадым.
Тагын кайткач, күрермен
дип
Туйганчы карамадым.
Талдан тартма ясый идем,
Тал буласын белмәдем.
Яннарыңда торыр идем,
Үләсеңне белмәдем.
Көзге искән җилләр белән
Таллар бөгелер инде.
Себер якларына карап,
Үзәк өзелер инде.
Карурманга кереп булмый
Шомырт чәчәк атмыйча.
Күңелемне бастыралмам
Барып күреп кайтмыйча.
Уйсу җиргә су җыела,
Анда кошлар коена.
Вакыт-вакыт газиз балам
Кайтыр кебек тоела.
Сикереп торып утырам,
Йокламыйм төннәремдә.
Мине хәсрәтләргә салдың
Картайган көннәремдә.
Зур диләр Казан каласын,
Салкын диләр һавасын.
Беркайчан да онытасы юк
Үзе үстергән баласын.
Агыйделнең сулары
Агадыр бит яр буйлап.
Минем гомерләрем үтәр,
Балам, гел сине уйлап.
Көттем, балам, хатларыңны,
Кулларыма алганчы.
Киткән чакта карап калдым,
Күз нурларым талганчы.
Шәһәрләрдән чыккан чакта
Карадым мин каерылып
Карамас идем каерылып
Балам калды аерылып.
Аллар да була икән,
Гөлләр дә була икән.
Баласын югалткан ана
Дивана була икән.
Үскән чакта ап-ак итеп
Күлмәкләр тегә идем,
Төнлә янында уянып
Чәбәкләп сөя идем.
Хәзер инде ул вакытлар
Юк алар, югалдылар.
Кайгылы йөрәкләремә
Тирән эз калдырдылар.
Магазиннарга барамын,
Шәлъяулык алам дип,
Хәзер инде сөйләшә алмыйм
Кайттыңмы, балам, диеп.
Кая барасыз дип сорыйм,
Халыкның күбесеннән
Кара кайгы сереме оча
Өемнең түбәсеннән.
Иртән чыккан кояш нуры
Тәрәзәләргә төшә
Балам диеп йөрәккәем
Бер сикерә, бер пешә.
Кара диеп карадылар
Минем кара кашыма.
Кайгы өстенә кайгы төште
Минем газиз башыма.
И балам, сагынам сине
Сагынуымны белмисең,
Бик сагынган көннәремдә
Төшемә дә кермисең.
Төшләремә кергәч белдем
Уйлаган уйларыңны,
Балам, барып күреп
кайттым
Йөрегән юлларыңны.
Себер ягының суларын
Йөзеп буйлады микән?
Чит илләрдә үләрмен дип
Берәр уйлады микән?


**МӨХӘРРИР Ө. У. АБДУЛЛИН.**

Учредитель: халык депутатларының Октябрь район Советы.



Газетада язмалары басылган авторларның фикерләре бу әле редакция фикере дигән сүз түгел.



**РЕДАКЦИЯНЕҢ АДРЕСЫ:** 423000, Норлат шәһәре, К. Маркс урамы, 19.
**ТЕЛЕФОННАР:** мөхәррир—2—12—14; 2—22—81, мөхәррир урынбасары—2—10—44, рус теленә һәм чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир урынбасарлары—2—15—63, социаль-экономика бүлеге—2—22—51, җаваплы секретарь—2—14—16, хатлар бүлеге һәм бухгалтерия—2—18—67.

Газетаны Нурзия ФӘСХЕТДИНОВА җыйды. Римма ГАНИЕВА верстка ясады. Клара БОБКОВА басты. Корректор Зөлфия ВӘЛИЕВА.

«Дуслык» газетасы атнаның сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга һәм рус, чуваш телләренә тәрҗемә ителә.
Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе буенча ТССР Дәүләт комитетының Октябрьның 50 еллыгы исемендәге Норлат-Октябрь типографиясе.
Күләме—1 басма табак. Заказ 107. Тираж 3413.